ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 176-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.Һ. Галиев, Р.Р. Нигъмәтуллин, Р.Г. Хөсәенов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 176-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре
2026 елның 8 июне
№ 639-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
М.Һ. Галиев,
Р.Р. Нигъмәтуллин,
Р.Г. Хөсәенов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2025, № 56 (I өлеш), № 75 (I өлеш); 2026, № 1 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Әлеге Законның 14 статьясының 1 өлешендә каралган финанс ярдәме, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башкасы каралмаган булса, тонусны күтәрә торган эчемлекләрдән гайре шикәрле эчемлекләрдән тыш, акцизлы товарлар җитештерүне һәм (яисә) реализацияләүне, шулай ук, гомумтаралган файдалы казылмалардан һәм минераль эчәргә яраклы сулардан тыш, файдалы казылмалар чыгаруны һәм (яисә) реализацияләүне гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларына күрсәтелә алмый.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законның 14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 9 апрелендәге 93-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Федераль законда тонусны күтәрә торган эчемлекләрдән гайре шикәрле эчемлекләр җитештерүне һәм (яисә) реализацияләүне гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектларының (алга таба – КУЭ субъектлары) финанс ярдәм чараларын алуына тыю төшереп калдырылган.

Татарстан Республикасында КУЭ субъектларына финанс ярдәме «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – ТР Законы) 14 статьясы нигезендә КУЭ субъектлары йөкләмәләре буенча субсидияләр, бюджет инвестицияләре, дәүләт гарантияләре һәм муниципаль гарантияләр бирү юлы белән Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле үзидарә органнарының җирле бюджеты акчалары, шулай ук, КУЭ субъектларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр бирелгән очракта, Россия Федерациясе бюджеты акчалары исәбеннән күрсәтелә.

Шул ук вакытта ТР Законының 9 статьясындагы 3 өлешенең гамәлдәге редакциясендә каралганча, КУЭ субъектларына финанс ярдәме акцизлы товарлар җитештерүне һәм (яисә) реализацияләүне гамәлгә ашыручы КУЭ субъектларына күрсәтелә алмый.

Моңа бәйле рәвештә закон проектында ТР Законының 9 статьясындагы 3 өлешенә шикәрле эчемлекләр (тонусны күтәрә торган эчемлекләрдән гайре) җитештерүчеләрне финанс ярдәме күрсәтелә алмый торган КУЭ субъектлары арасыннан төшереп калдыра торган охшаш үзгәреш кертү тәкъдим ителә.

Закон проектын гамәлгә ашыру салым йөкләнеше арткан вакытта җитештерү күләмнәренең кимү куркынычын киметергә мөмкинлек бирәчәк.

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.